**ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ РЕЛИГИОЗНАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ – ДУХОВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ МУСУЛЬМАН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**Мусульманская религиозная организация – учреждение среднего профессионального религиозного образования – Набережночелнинское медресе «Ак мечеть»**

«Утверждаю»
Директор
______________
(подпись)
Р.Ш. Шайхевалиев

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**по дисциплине «Татарский язык»**

Направление подготовки – «Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций мусульманского вероисповедания», наименование профиля – «Исламские науки и воспитание» (начальная подготовка)

Составитель:
кандидат филологических наук, доцент Р.И. Хазиев

**Согласовано**
Заместитель директора/проректор по учебной работе Набережночелнинского медресе «Ак мечеть» ________ Р.Р. Миниахметов
(подпись)
«___» ____________ 2015 г.

**Набережные Челны, 2015**

## Содержание

1. Пояснительная записка........................................................................................3
2. Наименование направления и профиля подготовки.............................................................3
3. Код и наименование дисциплины.......................................................................................3
4. Цель и задачи освоения дисциплины.................................................................................3
5. Место дисциплины  в структуре ООП................................................................................3
6. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины............3
7. Структура и содержание дисциплины..................................................................................4
7.1. Общая трудоемкость дисциплины......................................................................................4
7.2. Содержание дисциплины...................................................................................................5
8.Учебно-методическое и информационное обеспечение дисциплины................................8
8.1 Рекомендуемая литература.................................................................................................8
8.2.Программное обеспечение и Интернет-ресурсы...............................................................9
9. Материально-техническое обеспечение дисциплины..........................................................9
10. Методические рекомендации (материалы) для преподавателя.........................................9
11. Методические указания для обучающихся.......................................................................11
12. Контрольные материалы по внутрисеместровой, промежуточной аттестации и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы обучающихся.......................................14

## 1. Пояснительная записка

Программа предназначена для обучающихся 1 курса Мусульманской религиозной организации – учреждения среднего профессионального религиозного образования Набережночелнинского медресе «Ак мечеть» Централизованной религиозной организации – Духовного управления мусульман Республики Татарстан, по направлению подготовки «Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций мусульманского вероисповедания», наименование профиля – «Исламские науки и воспитание» (начальная подготовка).

Программа рассчитана на расширение и углубление теоретических и практических знаний по данному курсу, а именно на учение фонетического, лексического и грамматического строя татарского языка.

## 2. Наименование направления и профиля подготовки

Рабочая программа составлена согласно Образовательному стандарту среднего профессионального религиозного образования по направлению подготовки «Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций мусульманского вероисповедания», наименование профиля – «Исламские науки и воспитание» (начальная подготовка), утвержденного приказом Председателя Централизованной религиозной организации – Духовное управление мусульман Республики Татарстан, Муфтия от 12.11.2014 №74.

## 3. Код и наименование дисциплины

ОГС.Р.01. Татарский язык.

## 4. Цель и задачи освоения дисциплины

**Целью** освоения дисциплины «Татарский язык» является формирование у студентов знаний и навыков в области татарского языка.

**Задачи:**

-освоить лингвистические знания о нормах, областях татарского языкознания, обогащение и расширение круга используемых грамматических средств, необходимых для совершенствования устной и письменной речи;

-избегать грубых акцентологических, орфоэпических и интонационных ошибок в потоке речи;

-указать главнейшие принципы, по которым происходит изменение языка;

-изучение взаимосвязи языка и общества.

## 5. Место дисциплины в структуре ООП

Дисциплина «Татарский язык» относится к дисциплинам национально-регионального компонента общегуманитарных и социальных дисциплин (ОГС.Р.01).

Для освоения дисциплины «Татарский язык» обучающиеся используют знания, умения, навыки, сформированные в ходе изучения дисциплин «Татарский язык», «Татарская литература» в общеобразовательной школе и дисциплин «История Татарстана и татарского народа» в медресе.

Изучение дисциплины «Татарский язык» является необходимой основой для последующего изучения дисциплин «Татарская литература», «Старотатарская письменность», прохождения практики.

## 6. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины

***Национально-региональные компетенции***:

-Осознание самоценности татарской национальной культуры и необходимости ее сохранения и развития.

-Способность осуществлять устную и письменную коммуникацию на татарском языке, свободно изъясняться на литературном языке.

-Знание литературных традиций татарского народа.

-Знание основной классической терминологии по исламскому вероучению на татарском языке.

-Способность организации социально значимых мероприятий направленных на сохранение национальных традиций поволжских татар.

-Знание основных этапов исторического развития Татарстана с древнейших времен до наших дней, место и роль региона и населяющих его народов в истории России и в мировой истории в целом.

***Специальные педагогические компетенции***:

-Способность сочетать современные и традиционные для религиозного мусульманского образования методики и технологии, в том числе и информационные, для обеспечения качества учебно-воспитательного процесса по дисциплине (образовательному модулю) «Татарский язык».

В результате освоения дисциплины обучающийся должен:

***Знать:***

-культурные и религиозные традиции татарского народа;

-связь языка и религии;

-основные теоретические понятия лингвистики;

-особенности татарского языка;

-нормы культуры общения.

***Уметь:***

-грамотно разговаривать и писать по-татарски;

-использовать в речи лексику различных тематических групп с учетом сферы и целей общения;

-применять лингвистическую терминологию;

-анализировать языковые явления;

-осознавать характер связи между особенностями жизни, истории и культуры языкового коллектива и его языком;

-реализовывать на практике полученные знания и навыки.

***Владеть навыками:***

-толерантного восприятия социальных и культурных различий, уважительного и бережного отношения к историческому наследию и культурно-религиозным традициям;

-адекватного использования лексических ресурсов родного языка;

-организации культурно-просветительской деятельности;

-обобщения, анализа, восприятия информации;

-работы с учебной, научной и справочной литературой.

## 7. Структура и содержание дисциплины

### 7.1. Общая трудоемкость дисциплины составляет 132 часа

| Виды учебной работы | Всего часов | Семестр | |
|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 |
| Общая трудоемкость дисциплины | 132 | 64 | 68 |
| Аудиторные занятия | 66 | 32 | 34 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Лекции | 32 | 16 | 16 |
| Практические занятия (ПрЗ) | 34 | 16 | 18 |
| Семинары (С) | - | - | - |
| Лабораторные работы (ЛР) | - | - | - |
| Курсовая работа (КР) | - | - | - |
| Самостоятельная работа студентов (СРС) | 66 | 32 | 34 |
| Вид итогового контроля (контрольная работа, зачет, экзамен) | | контрольная работа | зачет |

## 7.2. Содержание дисциплины

| № п/п | Наименование и содержание тем занятий | Лекции (часы) | Практические занятия (часы) | Семинары (часы) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | **Кереш**<br>Курсның өйрәнү объекты, максат-бурычлары. Татар халкының этнотерриториаль төркемнәре һәм этник тамырлары. Татарлар һәм ислам. Дөньядагы телләр. Төрки телләрне төркемләү мәсьәләсе. Татар тел гыйлеме өлкәсендә эшләгән галимнәр һәм аларның хезмәтләре.<br>Татар теленең башка телләр һәм мәдәниятләр арасында тоткан урыны һәм әһәмияте. “Россия Федерациясе халыкларының телләре турында”гы һәм “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында”гы кануннар, Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында”гы канунны тормышка ашыру турындагы Дәүләт программасы. | 1 | 1 | |
| 2 | **Фонетика. Татар теленең аваз төзелеше**<br>Татар язуы тарихы. Сөйләм авазлары турында төшенчә. Сөйләм аппараты. Аваз артикуляциясе. Аваз-хәреф мөнәсәбәте. | 1 | 1 | |
| 3 | **Татар телендә аваз үзгәрешләре**<br>Аваз үзгәрешләре. Авазларның позицион (протеза, эпентеза, редукция) һәм комбинатор (аккомодация, | 1 | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ассимиляция, диссимиляция) үзгәрешләре. Сингармонизм законы. Авазлар чиратлашуы. | | | |
| 4 | **Татар телендә сузык һәм тартык фонемалар**<br>Авазларны төркемләү мәсьәләсе: сузык һәм тартык авазлар. Сузык һәм тартык авазларга характеристика. | 1 | 1 | |
| 5 | **Орфография һәм орфоэпия**<br>Әлифба. Орфография һәм орфоэпия кагыйдәләре-нормалары. | 2 | 2 | |
| 6 | **Лексикология**<br>Татар теленең сүзлек составы. Сүзлек составында бара торган үзгәрешләр. Алынма сүзләр:<br>-гарәп-фарсы алынмалары;<br>-рус теленнән һәм рус теле аша европа телләреннән кабул ителгән алынмалар.<br>Ислам диненә мөнәсәбәтле алынмаларның телебездә кулланылыш үзенчәлекләре. | 2 | 2 | |
| 7 | **Татар телендәге сүзләрнең тематик төркемнәре**<br>Татар телендә затны белдерүче сүзләр.<br>Татар телендә мөрәҗәгать итү формалары.<br>Татар телендә исәнләшү һәм саубуллашу. | 1 | 1 | |
| 8 | **Татар телендәге сүзләрнең тематик төркемнәре**<br>Татар телендә танышу.<br>Татар телендә үтенечне белдерүче сүзләр.<br>Татар телендә телефоннан сөйләшү.<br>“Сәламәтлек” темасы. | 1 | 1 | |
| 9 | **Татар телендәге сүзләрнең тематик төркемнәре**<br>Татар телендә туганлык мөнәсәбәтләрен белдерүче сүзләр.<br>“Йорт” темасы.<br>“Кибеттә” темасы.<br>“Мәктәптә” темасы. | 1 | 1 | |
| 10 | **Татар телендәге сүзләрнең тематик төркемнәре**<br>Ислам һәм телебез.<br>“Мәчеттә” темасы.<br>“Мәдрәсәдә” темасы. | 1 | 1 | |
| 11 | **Татар телендәге сүзләрнең тематик төркемнәре**<br>“Кием-салым” темасы.<br>“Ризыклар һәм җиләк-җимешләр” темасы. | 1 | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | “Сан” темасы. | | | |
| 12 | **Татар телендәге сүзләрнең тематик төркемнәре**<br>“Ел фасыллары” темасы.<br>“Һава торышы” темасы.<br>“Үсемлекләр дөньясы” темасы.<br>“Хайваннар дөньясы” темасы. | 1 | 1 | |
| 13 | **Татар телендәге сүзләрнең тематик төркемнәре**<br>“Һөнәр” темасы.<br>“Хезмәт кораллары” темасы.<br>“Газета-журналлар, радио һәм телевидение” темасы.<br>“Ял” темасы. | 1 | 1 | |
| 14. | **Грамматика**<br>Морфема. Грамматик мәгънә. Грамматик мәгънәләрне белдерүче грамматик чаралар. Аналитик һәм синтетик төзелешле телләр. Грамматик категорияләр. | 1 | 1 | |
| 15 | **Морфология**<br>Сүз төркемнәре турында төшенчә. Сүзләрне төркемләү принциплары. Сүз төркемнәренә характеристика.<br>Исем.<br>Сыйфат.<br>Сан.<br>Алмашлык.<br>Рәвеш. | 4 | 4 | |
| 16 | **Морфология**<br>Фигыль.<br>Татар телендә ярдәмлекләр. | 2 | 2 | |
| 17 | **Синтаксис. Гади җөмлә**<br>Сөйләм төзелеше системасы турындагы фән буларак синтаксис. Синтаксисның өйрәнү объекты. Сөйләмнең төп үзенчәлеге: хәбәрлек һәм модальлек. Сөйләм берәмлекләре. Синтаксис фәнендәге юнәлешләр. Татар синтаксис фәненең тарихы.<br>Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Сүзтезмә. Сүзтезмәләрнең төрләре. Җөмлә кисәкләре. Баш кисәкләр. Ия. Хәбәр. Иярчен кисәкләр. Аергыч. Тәмамлык. Хәлләр. Аныклагыч. Модаль кисәкләр. Эндәш сүз. Кереш сүзләр. Гади җөмлә модельләре. Гади җөмлә төрләре. Бер ярым хәбәрлекле җөмләләр. Хәбәрлек һәм модальлек. | 2 | 2 | |
| 18 | **Синтаксис. Кушма җөмлә**<br>Гади кушма җөмләләр. Иярченле кушма җөмләләр. Синтетик кушма җөмләләр. | 2 | 4 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Синтетик җөмләләрнең төп үзенчәлекләре. Синтетик җөмләләрне баш җөмләгә ияртүче чаралар. Синтетик җөмләләрне хәбәр булып килгән сүзгә карап төркемләү. Аналитик кушма җөмләләр. Аналитик җөмләләрне баш җөмләгә ияру чаралары буенча төркемләү. Иярчен җөмләләрне функциональ төркемләү һәм аларны үзгәртеп төзү. Тезмә кушма җөмләләр. Аерым җөмләләре үзара җыючы теркәгечләр аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр. Аерым җөмләләре үзара бүлгәләү теркәгечләре аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр. Аерым җөмләләре үзара каршылык теркәгечләре аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр. Аерым җөмләләре үзара санау интонациясе аша бәйләнгән кушма җөмләләр. Аерым җөмләләре үзара каршылык интонациясе аша бәйләнгән кушма җөмләләр. Катлаулы кушма җөмләләр. Күп тезмәле кушма җөмлә. Күп иярченле кушма җөмлә. Текст синтаксисы. Тезем. Чит сөйләмле текст. | | | |
| 19 | **Сөйләм осталыгы** Камил сөйләм оештыруда телнең эчке мөмкинлекләреннән дөрес файдалану. Вәгазь. | 6 | 6 | |
| | **Всего:** | 32 | 34 | |

## 8. Учебно-методическое и информационное обеспечение дисциплины

### 8.1. Рекомендуемая литература

**Основная литература**

1. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар теле: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәп өчен дәреслек (татар балалары өчен). – Казан: Мәгариф, 2004.

**Дополнительная литература**

2. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар әдәби теле (Рус бүлегенең татар студентлары өчен дәреслек). – Яр Чаллы: “Яр Чаллы типографиясе” ААҖ, 2005.
3. Абдуллина Р.С. Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре: монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.
4. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе. – Казан: Мәгариф, 2009.
5. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.
6. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2008.
7. Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер, 2001.
8. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Күнегүләр: Югары һәм урта уку йортлары өчен. – 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002.

9. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2002.

10. Сборник правил по татарскому языку для русскоязычных учащихся / Авт.-сост. Р.С. Нурмухаметова. – Казань: Гыйлем, 2012.

11. Татар теле дәресләре һәм сыйныфтан тыш эшләр: мәктәп укытучылары һәм филология факультеты студентлары өчен методик кулланма / Төзүчесе: Р.Х. Мөхиярова. – Казан: РИЦ, 2010.

12. Татарский язык. Татар теле / Авт.-сост. Г.Х. Гильманов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2007.

13. Фәтхуллова К.С., Юсупова Ә.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Татарча сөйләшик = Давайте говорить по-татарски = Lets speak tatar: уку әсбабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.

14. Харисова Ч.М. Татар теле. Теория, күнегүләр, тестлар. – Казан: Мәгариф, 2006.

15. Шаяхметова Л.Х. Татарский язык: интенсивный курс. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012.

16. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

17. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.

## 8.2. Программное обеспечение и Интернет-ресурсы

Программы:

Microsoft Word

ABBYY Fine Reader

Интернет-ресурсы:

-Электронная библиотека: http://koob.ru

-Аудио- и видео- пособия, учебное телевидение.

-Яндекс. Словари > гуманитарные науки.

## 9. Материально-техническое обеспечение дисциплины

Технические средства:

1. Видеопроектор.
2. Видеосистема для просмотра DWD дисков.
3. Стенд.
4. Интерактивная доска.

## 10. Методические рекомендации (материалы) для преподавателя

«Татарский язык» в сочетании с другими практическими и теоретическими дисциплинами должен обеспечить всестороннюю подготовку будущего преподавателя основ ислама, способного квалифицированно осуществлять свою профессиональную деятельность.

Изучение дисциплины «Татарский язык» осуществляется на аудиторных занятиях под руководством преподавателя и в ходе самостоятельной работы обучающихся. Существенным дополнением служат учебно-методические, иллюстративные материалы. Все виды деятельности обучающихся должны быть обеспечены доступным учебно-методическим материалом (учебниками, учебными и методическими пособиями). Учебные материалы должны быть доступны в печатном виде, а кроме этого могут быть представлены в электронном варианте.

В учебном процессе рекомендуется использовать следующую учебно-методическую литературу:

1. Әхмәтҗанова Р.Ф., Мөхиярова Р.Х. Мәктәптә эш кәгазьләрен өйрәнү: укытучылар, студентлар өчен методик кулланма. – Казан: РИО ГБУ “РЦМКО”, 2012.

2. Галләмов Ф.Г. Курс һәм чыгарылыш квалификация эшләрен язу методикасы. – Алабуга: АДПУ нәшрияты, 2009.

3. Марданшин М.М. Инструкции по составлению и ведению учебно-организационной и учебно-методической документации для МСПО. – Набережные Челны: Ислам Нуры, 2014.

4. Мөхиярова Р.Х. Туган тел һәм әдәбият белгечлеге буенча курс һәм чыгарылыш квалификация эшләре: студентлар өчен методик кулланма. – Казан: РИЦ “Школа”, 2008.

5. Хаҗиев Р.И. Татар ономастикасыннан фәнни хезмәт язуга методик кулланма (югары сыйныф укучылары өчен). – Яр Чаллы, 2011.

6. Ямбург Е.А. Что принесёт учителю новый профессиональный стандарт педагога? – М: Просвещение, 2014.

Стандарты:

Образовательные стандарты среднего профессионального мусульманского образования. – Казань, 2014.

Методы и приемы:

-историко-сопоставительный;
-структурный;
-статистический анализ;
-наблюдения;
-описательный.

Словари:

1. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

2. Гарипова Ф.Г. Татар топонимнары сүзлеге. – Казан: Идел-Пресс, 2010.

3. Зәйнуллин Җ.Г. Шәрык алынмалары сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 1994.

4. Ислам. Белешмә-сүзлек / Төзүче – З. Шәфигый; фәнни редактор – Р. Үтәбай-Кәрими. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

5. Мәхмутов М.И., Хәмзин К.З., Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча русча алынмалар сүзлеге: (Татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре). – Казан: Иман, 1993.

6. Русско-татарский словарь / Под редакцией Ф.А. Ганиева. – 4-е изд. испр. – М.: ИНСАН, 1997.

7. Сафиуллина Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф, 2001.

8. Сафиуллина Ф.С., Газизова Ф.М. Татарча-русча тезмә сүзләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.

9. Словарь исламских терминов. – Казань: Хузур-Спокойствие, 2014.

10. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005.

11. Татар теленең орфографик сүзлеге. – Казан: “Яңалиф” нәшрияты, 2004.

12. Татарский энциклопедический словарь / Главный редактор М.Х. Хасанов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1998.

13. Татарско-русский словарь: В 2-х т. Т.1 (А-Л). – Казань: Магариф, 2007.

14. Татарско-русский словарь: В 2-х т. Т.2 (М-Я). – Казань: Магариф, 2007.

15. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

16. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.

17. Хәлил Сәлим. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Алабуга: Алабуга пединституты нәшрияты, 2001.

Периодические издания:
Газеты:
«Ислам нуры».
«Мәгърифәт».
«Мәдәни җомга».

Журналы:
«Вопросы языкознания».
«Мәгариф».
«Мәйдан».
«Фән һәм мәктәп».
«Филологические науки».
«Шура».
«Казан утлары».
«Идел».

**Методика БРС**

**Порядок организации процедуры**

Успешность изучения дисциплины «Татарский язык» в 2-х семестрах, имеющей форму контроля *«зачет»*, оценивается исходя из 60 максимально возможных баллов.

**На текущий и рубежный контроль по дисциплине отводится 60 баллов.**

Рекомендуемый объем баллов на текущий контроль:

- *выполнение графика аудиторной работы по дисциплине и контроль посещаемости* – не более 20 баллов;
- *выполнение графика самостоятельной работы по дисциплине* – не более 20 баллов.

Рекомендуемый объем баллов на рубежный контроль:

- *семестровые контрольные мероприятия* – не более 20 баллов.

Обучающийся получает оценку «зачтено», если в ходе текущего и рубежного контролей он набрал по дисциплине не менее 51 балла.

При количестве рейтинговых баллов по дисциплине менее 51 для получения оценки «зачтено» и улучшения рейтинговых результатов обучающимся предоставляется возможность в течение последней недели семестра отработать пропущенный материал.

## 11. Методические указания для обучающихся

Основными видами аудиторных занятий данной специальности являются лекции и практические занятия.

Подготовка к практическим занятиям представляет собой внеаудиторную самостоятельную работу студента.

Самостоятельная подготовка к практическому занятию заключается в чтении соответствующего раздела учебника, первоисточников и выполнении письменных заданий.

Главными задачами этой подготовки обычно являются повторение теоретических знаний, усвоенных в рамках аудиторной работы; расширение и углубление знаний по теме занятия.

**Перечень вопросов для устного опроса**

1. Дөньядагы төрки телләрне санап чыгыгыз.
2. Татар теле башка телләр һәм мәдәниятләр арасында нинди урын тота һәм аны өйрәнүнең әһәмияте нәрсәдә?
3. Татар тел гыйлеме өлкәсендә эшләгән галимнәрне һәм аларның хезмәтләрен атагыз.

4. Сезгә мөселман дини оешмаларында хезмәт итү барышында татар теленең ярдәме тиячәкме? Ни рәвешле?
5. Күп телләр белүнең әһәмияте турында сөйләгез.
6. Ни өчен “Татарстанның төп байлыгы – халыклар дуслыгы” дибез?
7. Башка милләтләргә, телләргә, диннәргә һәм мәдәниятләргә карата түземле һәм ихтирамлы булуның әһәмияте нәрсәдә?
8. Сөйләм әдәбен ничек аңлыйсыз?
9. Сөйләмдә күзәтелә торган диалекталь хаталарга мисаллар атагыз.
10. Татар язуының кыскача тарихын сөйләп бирегез.
11. Татар әлифбасын яттан әйтегез.
12. Сузык авазларның акустик билгеләрен әйтегез.
13. Сөйләмдә авазлар нинди үзгәрешләргә дучар булалар?
14. Татар орфографиясенең кыен очракларын күрсәтегез.
15. Татар әдәби әйтелешенең бозып сөйләү очракларын һәм аның сәбәпләрен аңлатыгыз.
16. Гомумтөрки сүзләрнең фонетик һәм морфологик үзенчәлекләрен әйтегез.
17. Алынмалар нәрсә ул?
18. Чит сүзләр кабул итүнең сәбәпләре нәрсәдә?
19. Калькалар һәм алынмалар арасында аерма бармы?
20. Төрле сүз төркемнәренә хас грамматик категорияләрне атагыз.
21. Татар теленең морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре.
22. Татар җөмләсенә нинди сүз тәртибе хас?

**Задания для самостоятельной работы**

**1 нче бирем. Телләр турындагы кануннар һәм программалар.**

“Россия Федерациясе халыкларының телләре турында”гы һәм “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында”гы кануннар, Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында”гы канунны тормышка ашыру турындагы Дәүләт программасы белән якыннан танышыгыз. Гамәли дәрестә әлеге мәсьәләгә багышланган әңгәмәдә катнашыгыз.

**2 нче бирем. Түбәндә бирелгән фразеологик берәмлекләрнең мәгънәләренә ачыклык кертегез.**

Абруен күтәрү, акны карадан аеру, акылга утыру, Алла бәндәсе, Алла колы, Алла боерса, Аллага тапшыру, Алла куәт бирсен, Алла сакласын, әллә кем булу, әңгәмә кору, барып чыкмау, баскан җирдән ут чыгару, башы йомры, гамәлгә ашыру, дөньяга караш, җылы хәбәр, замана баласы, зирәк акыл, игелек күрү, иңне иңгә куеп, ис китү, йөрәккә яту, казан асу, канат кую, күз ачып йомганчы, лаек дип табу, мәңгегә күз йому, нәфес колы, нигез ташы, оятка калу, өйдәгесен тышка чыгармау, план кору, риза булу, сагызга әйләнү, сер саклау, соңгы сулыш, табадан яңа гына төшкән, тамырына балта чабу, тәнкыйть уты астына алу, тир түгү, тормыш итү, уен сүз күтәрмәү, уяу булу, үзәккә үтү, фаш итү, һушка килү, чабаталы морзалар, чамасын белү, читкә китү, шомарган таш, энә ташлар урын юк, эш кыру, юкны бар итү, яхшы күз белән карау, яшь түгү.

**3 нче бирем. Ватанга тугрылык, ата-анага һәм туган телгә ихтирам, белем алуның әһәмияте мәсьәләсенә багышланган мәкаль-әйтемнәрне җыйнагыз-барлагыз, аларның тәрбияви әһәмияте турында сөйләгез.**

Мәсәлән, “Белемдә бәхет, белемсезгә дөнья ләхет”, “Белем – нур, белмәү – хур”, “Дөньяда иң зур байлык – белем”, “Гыйлем алу – инә белән кое казу”, “Гыйлем өйрәнү – бишектән ләхеткә чаклы” һ.б.

**4 нче бирем. Хаталарны төзәтеп, сүзләрне күчереп языгыз.**

Абзас, августь, авто машина, аждаһа, анкау, аят, айкый чайкый, әһәң, архетектор, афикс, әфәт, балиг, бинокл, брилиант, вакум, васыят, волост, гаяр, гәҗәп, донья, дингез, җебшү, зология, зәхәр, идәрә, икетелелек, илхам, искармә, ишәрә, калеп, кахарман, кино актер, клуп, колон, маналог, махир, мәсәлә, метал, мили, носхә, амофон, аратор, оозис, обект, пасив, професор, пьесса, хәрәбә, хөкөм, шахит, шәхәр.

**5 нче бирем. Түбәндәге сүзләрнең язылышын истә калдырыгыз. Диктант итеп язып карагыз.**

Абруй, аръяк, ашханә, ашъяулык, әдәбият, әүвәл, әлифба, әмма, әмәл, әрвах, баштанаяк, бәрабәр, бәһа, берьюлы, борынгы, гадәт, гади, гаеп, гаилә, гаҗиз, галәм, гаскәр, гаять, гомер, гыйбадәт, гыйбарәт, гыйлем, даруханә, дәһшәтле, егет, җинаять, җөмһүрият, зәгыйфь, иганә, кабилә, кагыйдә, кардәш, канәгать, кодрәт, Коръән, мәгълүмат, маһир, мәгърур, мәйдан, мәкаль, мәнфәгать, мәхәббәт, мәшһүр, мәһабәт, мөнафикъ, мөстәкыйль, миһербан, мөһер, насыйп, нәгълә, нәзакәт, нәзарәт, нәкъ, нәшрият, нәүбәт, нәүмиз, нәүруз, никах, ниһаять, пакь, сәгать, сурәт, табигать, тәвәккәл, тәгъбир, тәкъдим, тәкъдир, тәүфыйк, тугры, фәкать, фигыль, хакыйкать.

**6 нчы бирем. Тиешле тыныш билгеләрен куеп, җөмләләрне күчереп языгыз.**

Тып-тын эссе бер көн иде. "Уазик" эче мунчага әйләнгән металл кызган кап-кара туфраклы колеяда тирбәлә-тирбәлә каядыр чыгып киттек. Мин үземне чит илдәге кебек хис иттем. Минем мондый табигатьне күргәнем юк иде. Без ике-өч метр биеклектәге сыек тал чыбыкларыннан торган куе урман эченнән барабыз. Юлның калкурак урыннарында көнчыгышка таба карап алам анда тау сузылган ул тау урман белән капланган. Тал куаклары тәбәнәкләнеп алган арада машина тәрәзәсеннән күреп алам алда иксез-чиксез болын куаклыклар дөнья тутырып чәчелгән зурлы-ваклы күлләр һәм борылмаларында куаклыклар белән өзгәләнеп калган елга... Безнең Татарстанда шундый урын бармыни (М. Мәһдиев).

**Татарские писатели и их произведения, рекомендуемые для изучения**

Гаяз Исхакый: "Сөннәтче бабай".
Габдулла Тукай: Сайланма әсәрләр.
Дәрдмәнд: "Исә җилләр".
Мәхмүт Галәү: "Мөһаҗирләр".
Галимҗан Ибраһимов: "Табигать балалары", "Казакъ кызы".
Сәгыйть Рәмиев: Сайланма әсәрләр.
Һади Такташ: Сайланма әсәрләр.
Мирхәйдәр Фәйзи: "Галиябану".
Кәрим Тинчурин: "Сүнгән йолдызлар", "Зәңгәр шәл".
Муса Җәлил: "Моабит дәфтәре".
Гадел Кутуй: "Тапшырылмаган хатлар", "Сагыну".
Фатих Кәрим: "Разведчик язмалары".
Нәби Дәүли: "Җимерелгән бастион", "Яшәү белән үлем арасында".
Зәки Нури: "Үлгәннәр дә үч алды".
Хәсән Туфан: Сайланма әсәрләр.
Сибгат Хәким: Сайланма әсәрләр.
Габдрахман Әпсәләмов: "Ак төннәр", "Ак чәчәкләр".
Гомәр Бәширов: "Туган ягым – яшел бишек".
Гариф Ахунов: "Ардуан батыр".
Әмирхан Еники: Сайланма әсәрләр.
Шәйхи Маннур: "Агымсуларга карап".
Аяз Гыйләҗев: "Җомга көн, кич белән...", "Әтәч менгән читәнгә", "Өч аршын җир".

Нурихан Фәттах: “Сызгыра торган уклар”, “Итил суы ака торур”.

Мөхәммәт Мәһдиев: “Фронтовиклар”, “Кеше китә – җыры кала”, “Торналар төшкән җирдә”, “Бәхилләшү”.

Эдуард Касыймов: “Чулман – оныклар дәрьясы”.

Фәнис Яруллин: “Җилкәннәр җилдә сынала”.

Мәдинә Маликова: “Шәфкать”.

Туфан Миңнуллин: “Әниләр һәм бәбиләр”.

Роберт Батулла: “Кичер мине, әнкәй”.

Фоат Садриев: “Бәхетсезләр бәхете”.

Вахит Имамов: “Казан дастаны”, “Утлы дала”.

## 12. Контрольные материалы по внутрисеместровой, промежуточной аттестации и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы обучающихся

### Тестовые задания

### Вариант №1

Инструкция: выберите наиболее полный и верный ответ на каждое их утверждений и отметьте его на бланке, обведя кружком или зачеркнув. Не рекомендуется долго размышлять над каким-либо одним утверждением.

**1. Телнең авазлар системасын, аларның үзгәрешен өйрәнә торган тармак**

1) Фонетика
2) Лексикология
3) Сүзьясалыш
4) Грамматика

**2. Сузык аваз**

1) б
2) т
3) ө
4) л

**3. Алгы рәт сузык аваз**

1) а
2) у
3) ү
4) ы

**4. Рус алынмасы**

1) Абруй
2) Кыйбла
3) Хәрабә
4) Өстәл

**5. Латин алынмасы**

1) Мич
2) Башмак
3) Лингвистика
4) Чалма

**6. Кушма сүз**

1) Ярымутрау
2) Урман
3) Авыл
4) Кала

**7. Ясалма сүз**
1) Тимер
2) Авылдаш
3) Күл
4) Сүз

**8. Исем сүз төркеменә караган сүз**
1) Матур
2) Мулла
3) Тиз-тиз
4) Өчәү

**9. Күрсәтү алмашлыгы**
1) Теге
2) Кем
3) Әллә нинди
4) Беркайчан

**10. Процессны белдерүче сүз**
1) Сан
2) Алмашлык
3) Бәйлек
4) Фигыль

**11. “Татар синтаксисы” (Казан, 2008) хезмәтенең авторы**
1) М.З.Зәкиев
2) Т.Н.Галиуллин
3) Г.Ф.Саттаров
4) М.Х.Бакиров

**12. Синтаксис ...**
1) тел һәм фикерләүне өйрәнә
2) телнең функцияләрен өйрәнә
3) ялгызлык исемнәрне өйрәнә
4) сөйләм төзелешен өйрәнә

**13. Тәмамланган уйны белдерүче сүз яки сүзләр тезмәсе ...**
1) сүз төркеме дип атала
2) килеш категориясе дип атала
3) җөмлә дип атала
4) заман категориясе дип атала

**14. Җөмләнең баш кисәкләре**
1) Ия һәм хәбәр
2) Тәмамлык һәм аергыч
3) Тәмамлык һәм хәл
4) Аергыч һәм хәл

**15. Процессның яки билгенең булу яки үтәлү урынын белдерә торган кисәк**
1) Вакыт хәле
2) Урын хәле
3) Рәвеш хәле
4) Күләм хәле

**16. Аныклагыч ачыклап килгән сүз**
1) Эндәш сүз
2) Кереш сүз
3) Аныкланмыш
4) Сүзтезмә

**17. Төрки тел**
1) Рус
2) Япон
3) Поляк
4) Татар

**18. Славян теле**
1) Башкорт
2) Белорус
3) Кыргыз
4) Үзбәк

**19. Фин-угор теле**
1) Испан
2) Немец
3) Чех
2) Удмурт

**20. Гарәп теле ... төркеменә карый**
1) семит
2) роман
3) албан
4) һинд

## Вариант №2

Инструкция: выберите наиболее полный и верный ответ на каждое их утверждений и отметьте его на бланке, обведя кружком или зачеркнув. Не рекомендуется долго размышлять над каким-либо одним утверждением.

**1. Телнең сүзлек байлыгын, аның үсешен һәм үзгәрешен өйрәнә торган тармак**
1) Фонетика
2) Лексикология
3) Сүз ясалышы
4) Грамматика

**2. Арткы рәт сузык аваз**
1) ә
2) ө
3) ы

4) Ү

**3. Тартык аваз**
1) а
2) ә
3) к
4) и

**4. Гарәп алынмасы**
1) Бүрәнә
2) Сумала
3) Мичкә
4) Рәхмәт

**5. Инглиз алынмасы**
1) Футбол
2) Арыш
3) Уҗым
4) Эскерт

**6. Тамыр сүз**
1) Өскорма
2) Таш
3) Өчпочмак
4) Ярымүткәргеч

**7. Парлы сүз**
1) Арыш
2) Тарак
3) Чирәм
4) Тимер-томыр

**8. Предметны атаучы сүз**
1) Исем
2) Сыйфат
3) Рәвеш
4) Теркәгеч

**9. Сыйфат сүз төркеменә караган сүз**
1) Ул
2) Кып-кызыл
3) Кырык
4) Бара

**10. Зат алмашлыгы**
1) Бу
2) Нигә
3) Без
4) Беркайчан да

**11. Бирелгән җөмләдәге эндәш сүзләрне билгеләгез:** *Ах, җырлар, җырлар, сез кеше йөрәген нәрсә генә эшләтмисез!*

1) Җырлар, җырлар
2) Сез
3) Кеше йөрәген
4) Эшләтмисез

**12. Ике яки икедән артык хәбәрлеге булган җөмлә ...**
1) сүзтезмә дип атала
2) гади җөмлә дип атала
3) кушма җөмлә дип атала
4) текст дип атала

**13. Бирелгән җөмләдәге аерым җөмләләрне үзара бәйләүче чара:** *Арыш артыннан арпа өлгерде, бодай, солы саргая башлады, борчакны алыр вакыт җитте.*
1) Җыючы теркәгеч
2) Бүлүче теркәгеч
3) Каршы куючы теркәгеч
4) Санау интонациясе

**14. Күрсәтелгән җөмләдәге аерым җөмләләрне үзара бәйләп килгән теркәгечнең төре:** *Яңгыр туктады, **ләкин** кояш күренмәде.*
1) Каршы куючы теркәгеч
2) Бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә
3) Җыючы теркәгеч
4) Бүлүче теркәгеч

**15. Иярченле кушма җөмлә составындагы бәйләүче чараның төре:** ***Кайда*** *ныклы тәртип юк,* ***шунда*** *тәртипсезлек хөкем сөрә.*
1) Синтетик бәйләүче чара
2) Аналитик бәйләүче чара
3) Санау интонациясе
4) Җыючы теркәгеч

**16. Тоташ сөйләмнең иң зур формасы**
1) Сүз
2) Сүзтезмә
3) Җөмлә
4) Текст

**17. Төрки телне табыгыз**
1) Ингуш
2) Гарәп
3) Чуваш
4) Француз

**18. Төрки булмаган тел**
1) Төрекмән
2) Ногай
3) Гагауз
4) Латыш

**19. Фарсы теле ... төркеменә карый**
1) Иран

2) Балтик
3) Кельт
4) Тохар

**20. Бөтендөнья аралашу теле**
1) Словак
2) Инглиз
3) Македон
4) Швед

**Комплект заданий для контрольной работы**

**Контроль эш биремнәре:**

**1 нче бирем.**
1. Сөйләм культурасын ничек аңлыйсыз?
2. Бирелгән диалогны дәвам итеп языгыз.
– Әс-сәламү галәйкүм! Рафикъ хәзрәт мәдрәсәдәме?
– Вә галәйкүмүс-сәлам! Мәдрәсәдә. Түргә узыгыз.
– Рәхмәт, Азат хәзрәт. Аны күрергә мөмкинме?
– Әлбәттә. Рафикъ хәзрәт, сезне сорыйлар!
– ...

**2 нче бирем.**
1. Сөйләм культурасы белән стилистика арасында бәйләнеш бармы?
2. Бирелгән диалогны дәвам итеп языгыз.
– Габдулла, син кайсы мәдрәсәдә белем аласың?
– Мин җөмһүриятебезнең Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан “Ак мәчет” мөселман мәдрәсәсендә дини гыйлем үзләштерәм.
– Анда нинди фәннәр укытыла?
– Без анда төрле фәннәрне өйрәнәбез. Мәсәлән, гарәп теле, фикъһе, хәдис, гакыйдә, сира, әхлак, тәфсир, диннәр тарихы, татар теле, татар әдәбияты һәм башка фәннәрне.
– ...

**3 нче бирем.**
1. Татар телендәге гарәп-фарсы алынмаларының кулланылыш үзенчәлекләре.
2. Түбәндәге алынма сүзләр татар теленә кергәндә нинди фонетик үзгәрешләргә дучар булганнар? Газет, өстәл, сумала. Әлеге закончалыкларны аңлатыгыз.

**4 нче бирем.**
1. Телебезгә рус (европа) алынмалары үтеп керүнең сәбәпләре һәм юллары.
2. Татар телендә әйтелеш белән язылыш арасында аерма булган сүзләргә мисаллар туплап языгыз. Орфоэпия кагыйдәләрен белүнең әһәмияте нәрсәдә?

**Күнегүләр:**

**1 нче күнегү.**
Текстны рус теленә тәрҗемә итегез, астына сызылган сүзләргә фонетик анализ ясагыз.
Ислам – дөньяда иң киң таралыш алган диннәрнең берсе. Алжир, Әфганстан, Бангладеш, Бахрейн, Берләшкән Гарәп Әмиратлары, Иордания, Ирак, Иран, Йәмән Гарәп Республикасы, Катар, Кувейт, Ливан, Ливия, Мисыр, Сирия, Судан, Сөгуд Гәрабстаны,

Төркия һәм Тунис кебек илләрдә ул аеруча зур сәяси-иҗтимагый әһәмияткә ия. Исәпләүләрдән күренгәнчә, 120 илдә 1,5 миллиард чамасы халыкны берләштергән мөселман берләшмәләре бар. Бөтен мөселманнарның яртысы диярлек Төньяк Африкада гомер итә. Иң күп мөселман халкы булган ил – Индонезия.

Гомумән, кемнәр соң ул мөселманнар?

Әлеге сорауга җавапны “Тәүбә” сүрәсенең 122 нче аятендә табабыз: “Алар гөнаһлардан тәүбә итәрләр, ихлас гыйбадәт кылырлар, һәрвакыт Аллаһуга хәмед әйтеп ураза тотарлар, рөкугъ сәҗдә кылып намаз укырлар, яхшы эшләргә өндәрләр, бозык эшләрдән тыярлар. Вә Аллаһ хөкемнәрен сакларлар. Аллаһ сызган сызыктан чыкмаслар”.

Россия Федерациясендә дә Ислам динен тотучы халыклар шактый (20 млн. чамасы). Алар, нигездә, Идел-Урал буйларында (Татарстанда һәм Башкортстанда) һәм Төньяк-Көнчыгыш Кавказ регионында (Дагстанда, Ингушетиядә, Чеченстанда) яшәүче халыклар (Р. Хаҗиев).

**2 нче күнегү.**

Телгә багышланган фразеологизмнарны барлап языгыз: телгә алу, теле юк, телне кыскарту, телеңнең тоткасы юк, телеңә хуҗа булу... Аларның мәгънәләрен аңлатыгыз.

**3 нче күнегү.**

“Изгелек эзсез югалмый” дигән темага язмача монолог төзегез.

**4 нче күнегү.**

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” ярдәмендә иман, намус, мулла, моң, олы, саф, табигать, тараф, тоту, төс, төшү, фарыз, челтәр, энә кебек сүзләрнең мәгънәләрен ачыклагыз һәм язып алыгыз. Алар ярдәмендә җөмләләр төзегез.

**5 нче күнегү.**

Түбәндәге сүзләр арасыннан гарәп-фарсы алынмаларын билгеләгез.

Абонент, автовокзал, алман, армия, афәт, балык, бокс, боцман, вафат, гайрәт, газиз, газраил, гараж, дәүләт, дружина, дүшәмбе, җәза, җәмгыять, җәмәгать, завод, иҗтимагый, казый, каләм, күл, мәдәният, мәдрәсә, мәхрүм, мәчет, мозаика, морж, мотор, мөгаллим, мөдир, мөселман, мөслим, мөфти, мөхбир, мулла, намаз, тезис, телевизор, телефон, фәрештә, футбол, хәлифә, хәреф, шигърият, шлюз, экономика, этаж, һәвәскәр.

**6 нчы күнегү.**

Саф лексик омонимнарга, омофоннарга, омографларга һәм омоформаларга мисаллар уйлап языгыз.

**7 нче күнегү.**

Түбәндәге сүзләрнең антонимнарын табыгыз.

Аз, акыллы, арзан, биек, быел, зур, калын, карт, озын, сәламәт, тар, тиз, тирән, тук, уңай, чиста, эссе, юмарт, якты, яңа, яхшы.

**8 нче күнегү.**

Бирелгән сүзләрдән синонимик оялар төзегез.

Үлү, яшәү, матур, азат, күп.

Алар катнашында текст төзегез.

**9 нчы күнегү.**

Актив кулланылышлы һәм искергән сүзләргә, неологизмнарга мисаллар уйлап языгыз.

Актив сүзләр: әти, әни, бала, икмәк, су...

Искергән сүзләр: каган, тархан, ясак...

Неологизмнар: айпад, айфон, ксерокс, супервайзер, принтер...

**10 нчы күнегү.**

Армия, кәгазь, кардәш, нефть, уй сүзләрен килеш, китап, тау, кияү, металл, көй сүзләрен тартым белән төрләндерегез.

**11 нче күнегү.**

Түбәндәге сүзләрнең язылыш принцибын билгеләгез.

Ак – агы, АКШ, алмагач, ашъяулык, БМО, буйсыну, бушбугаз, “ВАЗ” машинасы, “Ватаным Татарстан” газетасы, газсыман, дәва, дүртьяклы, озын, өйалды, өч килограмм алма, “Казан утлары” журналы, Казык йолдыз, каләм, кәгазь, кып-кызыл, малай-шалай, пиджак, сап – сабы, сап-сары, тозсыз, унике, Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, 1 нче рәт.

**12 нче күнегү.**

Аеру билгесен (ь, ъ) дөрес куеп, сүзләрне күчереп языгыз.

Ал...япма, бер...юлы, бер...ялгызы, бер...яклы, дүрт...юллык, ел...язма, йөз...яшәр, көн...як, кул...югыч, күп...еллык, Мәр...ям, мең...еллык, төн...як, ун...еллык, һәр...як.

**13 нче күнегү.**

Түбәндәге сүзләргә күплек кушымчалары ялгап языгыз.

Авиамодель, акрополь, артель, артикль, апрель, бинокль, вексель, вермишель, июль, портфель, спектакль.

Аллея, батарея, галантерея, гинея, идея.

Авиация, автономия, агитация, агрономия, академия, акция, армия, индукция, инстанция, педагогия, пенсия, территория, традиция.

Вече, желе, кафе, кофе, купе.

Жюри, иваси, калибри, мари, такси.

Аять, бәгырь, бронь, бунтарь, верфь, повесть.

Лицей, мавзолей, музей, хоккей, юбилей.

**14 нче күнегү.**

Бирелгән җөмләләргә тулы синтаксик, астына сызылган сүзләргә морфологик анализ ясагыз.

Җырым белән дусны иркәләдем, җырым белән <u>җиңдем</u> дошманны (М. Җәлил). Мин <u>шуны</u> гына беләм: ел елга охшамый (Г. Тукай). Сөйгән улы <u>сугыштан</u> кайтмау аны бөтенләй аяктан екты (Г. Әпсәләмов). Болында үлән ни хәтле, <u>анда</u> кеше шул хәтле (Г. Бәширов). Хәзер <u>директор</u> үзе килергә тиеш, шуңа чаклы көтеп торыгыз (Ш. Камал). <u>Минем</u> атым юаш булганлыктан, бер малайга җигеп бирәбез (Һ. Такташ). Заман ничек булса, <u>бүрегеңне</u> шулай ки (мәкаль). <u>Быел</u> игеннәр бик уңган булса да, көннәр коры булу сәбәпле, ялан эше үз вакытында тәмам булды (Г. Ибраһимов). Әгәр дә җирдә яхшылык та, <u>җылылык</u> та булмаса, тормыш та булмас иде (Г. Тукай). Яз җиткән булуга карамастан, иртәнге суыкта аяк асты <u>коп-коры</u> (И. Гази). Син адаштың, ләкин син яхшы идең, синең яхшы иде күңелең, тик <u>белмәдең</u> тормыш баткагыннан ялгыз чыгу мөмкин түгелен (Һ. Такташ).

**15 нче күнегү.**

Текстны татар теленә тәрҗемә итегез.

Следующая стадия подготовки проповеди – ее обдумывание. На этой стадии имам перепроверяет факты, уточняет мысли, приводит их в порядок, связывает детали, поясняет сложные для прихожанина понятия, располагает весь материал в логической

последовательности. Поскольку это творческий процесс, то какой-либо единой схемы не существует. Проповедь может начинаться с постановки проблемы, озвучивания айата, хадиса, мудрого изречения, истории, газетной статьи и пр. Все зависит от фантазии имама и потребности прихожан. Чтобы упростить процесс обдумывания и задать ему верное направление, проповедник может себе задавать вопросы: «Что я хочу донести до прихожан в этой проповеди? Какова ее главная мысль? Какой вывод можно извлечь из приведенных фактов? Какое отношение имеет тот или иной аргумент к идее, которую я хочу донести?» (Р. Адыгамов).

**Темы рефератов**

1. Сүз сәнгатен өйрәнү тарихы.
2. Матур сүз – дөрес сүз.
3. Вәгазь – имамның төп коралы.
4. Коръән халыклар һәм телләр яратылышы турында.
5. Татар телендәге гарәп-фарсы алынмалары.
6. Халыклар дуслыгы – Татарстанның төп байлыгы.
7. Татар теленең төрки телләр арасында тоткан урыны.
8. Татар телендә нәшер ителә торган газета-журналлар теленә күзәтү.
9. Радио һәм телевидение теле – тел торышының бер күрсәткече.
10. Матур һәм күркәм исемнәр кушыйк.
11. Ислам – тынычлыкка һәм яхшылыкка өндәүче дин.
12. Г. Тукай – татар әдәби теленә нигез салучы әдипләребезнең берсе.
13. Г. Ибраһимов – язучы һәм телче-галим.

*Әдәбият:*


1. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар әдәби теле (Рус бүлегенең татар студентлары өчен дәреслек). – Яр Чаллы: “Яр Чаллы типографиясе” ААҖ, 2005.
2. Абдуллина Р.С. Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре: монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.
3. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе. – Казан: Мәгариф, 2009.
4. Абдуллина Р.С. Сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.
5. Саттар-Мулилле Г.Ф. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). – Казан: Раннур, 1998.
6. Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер, 2001.
7. Татарский язык. Татар теле / Авт.-сост. Г.Х. Гильманов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2007.
8. Фәтхуллова К.С., Юсупова Ә.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Татарча сөйләшик = Давайте говорить по-татарски = Lets speak tatar: уку әсбабы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.
9. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.
10. Юсупов Р.А. Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.
11. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.


**Список вопросов к зачету**

1. Татар халкының этник тамырлары.
2. Татарлар һәм ислам. Ислам һәм телебез.
3. Төрки телләрне төркемләү мәсьәләсе. Карашлар.
4. Татар телендәге сөйләм авазларына характеристика бирергә.
5. Татар телендә аваз үзгәрешләре.
6. Татар теленең сүзлек составы, анда бара торган үзгәрешләр.

7. Искергән сүзләр (архаизмнар).
8. Яңа сүзләр (неологизмнар).
9. Алынмалар кабул итү.
10. Интернациональ сүзләр.
11. Терминнар һәм терминология.
12. Лексикография. Сүзлекләрнең төрләре, алар белән эшләү тәртибе.
13. Ономастика тармагы. Мөселман исемнәре.
14. Татар телендә затны белдерүче сүзләр.
15. Татар телендә мөрәҗәгать итү формалары.
16. Татар телендә исәнләшү һәм саубуллашу.
17. Татар телендә танышу.
18. Татар телендә үтенечне белдерүче сүзләр.
19. Татар телендә телефоннан сөйләшү.
20. Татар телендә туганлык мөнәсәбәтләрен белдерүче сүзләр.
21. “Сәламәтлек” темасына диалог төзергә.
22. “Йорт” темасына диалог төзергә.
23. “Һөнәр” темасына диалог төзергә.
24. “Мәктәптә” темасына диалог төзергә.
25. “Мәчеттә” темасына диалог төзергә.
26. “Мәдрәсәдә” темасына диалог төзергә.
27. “Кием-салым” темасына диалог төзергә.
28 “Ризыклар һәм җиләк-җимешләр” темасына диалог төзергә.
29. “Сан” темасына диалог төзергә.
30. “Кибеттә” темасына диалог төзергә.
31. “Ел фасыллары” темасына диалог төзергә.
32. “Һава торышы” темасына диалог төзергә.
33. “Үсемлекләр дөньясы” темасына диалог төзергә.
34. “Хайваннар дөньясы” темасына диалог төзергә.
35. “Хезмәт кораллары” темасына диалог төзергә.
36. “Газета-журналлар, радио һәм телевидение” темасына диалог төзергә.
37. “Ял” темасына диалог төзергә.
38. Исем сүз төркеме.
39. Сыйфат сүз төркеме.
40. Сан сүз төркеме.
41. Алмашлык сүз төркеме.
42. Рәвеш сүз төркеме.
43. Фигыль сүз төркеме.
44. Бәйләгеч сүз төркемнәре.
45. Модаль сүз төркемнәре.
46. Сүзтезмә.
47. Сүзләр бәйләнеше.
48. Гади җөмлә.
49. Җөмлә кисәкләре.
50. Кушма җөмлә.
51. Тезмә кушма җөмлә.
52. Иярченле кушма җөмлә.
53. Катлаулы кушма җөмлә.
54. Катнаш кушма җөмлә.
55. Текст.
56. Сүз сәнгате.
57. Камил сөйләм оештыруда телнең эчке мөмкинлекләреннән дөрес файдалану.
58. Вәгазь.